МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2018 Казан ш. № 249

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында килешү формасын раслау хакында

"Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар турында" 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт күчерү өчен боерык бирәм:

1. 1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында килешүнең әлеге Боерыкка 1 нче кушымтада каралган типик формасын расларга;

2. Территориаль үсеш идарәсенең муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлегенә (Э.М. Каргинга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының Башкарма комитетлары белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында килешүләр әзерләүне;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының Башкарма комитетларыннан әлеге боерыкның таләпләрендә һәм "Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар турында" 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында каралган хисапларны туплау.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының "Авыл җирлегенә грант бирү турында шартнамә һәм гранттан файдалану турында финанс хисабы формаларын раслау хакында" 2016 елның 28 октябрендәге 339 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Н.А. Таркаевка йөкләргә.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Министр Ф.С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
04.06.2018, 249 номерлы
боерыгына кушымта

Типлаштырылган формасы

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирү турында**
**КИЛЕШҮ**
**№ __________**

Казан ш.

«____»______________, 20____ел №_______

Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына максатчан билгеләнешле бүтән бюджетара трансферт бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары аннары аларны Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына җибәрү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) исеменнән, ул Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы булып тора, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре" 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә таянып эш йөртүче Татарстан Республикасы икътисад министры ___________________________, бер яктан, һәм ___________________ муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) исеменнән Уставка/Нигезләмәгә таянып эш йөртүче ___________________ муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе __________________________, икенче яктан (алга таба икесе дә бергә килгәндә – Яклар), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар турында" 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карары (алга таба – Тәртип) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20____ елның ____________, ________ номерлы күрсәтмәсенә нигезләнеп, түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне төзеделәр.

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы Татарстан Республикасы бюджетыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чигендә Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы булып торган Татарстан Республикасы авыл җирлекләре бюджетларына җибәрү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүтән бюджетара трансфертны (алга таба – Бүтән бюджетара трансферт)

бюджетлар чыгымнары классификациясе кодлары буенча бирүдән гыйбарәт: Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче коды _______, бүлекчә ________, максатчан статья _________, әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар ________ косгу___________.

1.2. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә Бүтән бюджетара трансферт бирү Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә түбәндәге максатларга грантлар бирүгә еллык республика конкурсы (алга таба – Конкурс) нәтиҗәләре буенча башкарыла:
а) Татарстан Республикасы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы авыл халкының яшәү дәрәҗәсен арттыру буенча эшчәнлеген стимуллаштыру;
б) Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең социаль әһәмиятле проблемаларын хәл итү;
в) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен өстәмә ресурслар җәлеп итү механизмнарын камилләштерү.
1.3. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең яшәешен турыдан-туры тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгыту, авыл җирендә урнашкан торак пунктларның социаль инфраструктура һәм тышкы төзеклек объектлары белән җиһазлау чараларын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең социаль әһәмиятле башка мәсьәләләрен хәл итү өчен Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсы җиңүчеләренә Бүтән бюджетара трансферт бирү әлеге Килешүгә 1 нче кушымтада каралган чаралар исемлегенә һәм әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада каралган Бүтән бюджетара трансферт акчаларын тоту юнәлешләренә ярашлы рәвештә башкарыла, әлеге кушымталар Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

## 2. Бүтән бюджетара трансферт бирү һәм күчерү тәртибе, шартлары

.

2.1. Бүтән бюджетара трансферт тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чигендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «___» ___________, 20__ ел, №_______ боерыгы белән расланган Бүтән бюджетара трансферт бүленеше нигезендә бирелә.
2.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетына 20___ елда бирелә торган Бүтән бюджетара трансфертның гомуми күләме ________ (_______________________________________) сум _________ тиен тәшкил итә.
2.3. Бүтән бюджетара трансферт түбәндәге шарт булганда бирелә:
а) Татарстан Республикасы авыл җирлекләре бюджетларына бүтән бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районының чыгым йөкләмәсен билгели торган билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән Татарстан Республикасы муниципаль районы муниципаль хокукый акты булу;
б) Татарстан Республикасы муниципаль районының бүтән бюджетара трансфертлардан файдалану турында берләштерелгән хисап бирү турында йөкләмәсе булу;
2.4. Әлеге Килешүнең 2.3 пунктында каралган Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының үтәлүен раслый торган документлар Башкарма комитет тарафыннан Министрлыкка бер тапкыр тапшырыла.

2.5. ___________________ муниципаль районы Башкарма комитетына Бүтән бюджетара трансферт күчерү Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органында җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтелү өчен Килешү имзаланган датадан 10 эш көне эчендә ачылган счетына башкарыла.

## 3. Якларның үзара мөнәсәбәте

3.1. Министрлык түбәндәгеләргә бурычлы:
3.1.1. _______________ муниципаль районы бюджетына Бүтән бюджетара трансферт бирүне әлеге Килешүдә билгеләнгән Бүтән бюджетара трансферт бирү тәртибен саклап һәм аны бирү шартларын Башкарма комитет тарафыннан үтәп тәэмин итәргә.
3.1.2. _______________ муниципаль районы бюджетына Бүтән бюджетара трансферт бирүне әлеге Килешүдә билгеләнгән Бүтән бюджетара трансферт бирү тәртибен саклап һәм аны бирү шартларын Башкарма комитет тарафыннан үтәп тәэмин итәргә.
3.1.3. Россия Федерациясе законнарына нигезләнеп Тәртип нигезендә бирелгән Бүтән бюджетара трансфертның максатчан файдаланылуын тикшереп торуны Татарстан Республикас Финанс министрлыгы белән берлектә гамәлгә ашырырга.
3.1.4. Бүтән бюджетара трансфертның максатчан файдаланылуын раслый торган документларны тикшерүне гамәлгә ашырырга.
3.1.5. Башкарма комитетка әлеге Килешүне үтәү белән бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмаларны әлеге Килешүнең 3.4.1 пункты нигезендә Башкарма комитеттан мөрәҗәгать алынган көннән алып 30 эш көне эчендә җибәрергә.
3.1.6. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны башкарырга.
3.2. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:
3.2.1. Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының һәм Килешүдә каралган бүтән бурычларның Башкарма комитет тарафыннан үтәлешен, шул исәптән Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларын Башкарма комитет үтәве белән бәйле бухгалтерлык исәп-хисабы һәм беренчел документация күрсәткечләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм материалларны Башкарма комитеттан соратып алырга.
3.2.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.
3.3. Башкарма комитет түбәндәге йөкләмәләрне ала:
3.3.1. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 7 числосына кадәрге срокта Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы Бүтән бюджет трансферты булган чыгымнар турында вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан таныкланган хисапны, аның язма формасы әлеге Килешүгә 3 нче кушымтада каралган, тотылган акчаны раслый торган документларның күчермәләре белән бергә квартал саен кулдан тапшырырга.
3.3.2. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 7 числосына кадәрге срокта Министрлыкка бюджет чараларын баш бүлүченең, бүлүченең, алучының, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторының, администраторының, бюджет керемнәре баш администраторының, администраторының бюджетын үтәү турындагы хисабын (форма ОКУД 0503127 (Россия Финанс министрлыгының 2010 елның 28 декабрендәге 191н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү турында еллык, кварталлык һәм айлык хисаплар төзү һәм тапшыру тәртибе турында кулланма нигезендә) квартал саен кулдан

тапшырырга. Министрлыкка хисап, финанс органы тарафыннан таныкланып, кәгазьдә кулдан тыпшырыла.
3.3.3. Хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәрге срокта Министрлыкка әлеге Килешүгә 3 нче, 4 нче кушымталарда каралган һәм Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Бүтән бюджетара трансферттан файдалану турындагы йомгак финанс хисабын кулдан тапшыруны тәэмин итәргә.
3.3.4. Соратылган очракта, Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының һәм әлеге Килешүдә каралган бүтән бурычларның Башкарма комитет тарафыннан үтәлешен, шул исәптән Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларын Башкарма комитет үтәве белән бәйле бухгалтерлык исәп-хисабы һәм беренчел документация күрсәткечләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм материалларны Министрлыкка тапшыруны тәэмин итәргә.
3.3.5. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча файдаланылмаган бүтән бюджетара трансфертны әлеге Килешүнең 4.4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга.
3.3.6. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны башкарырга.
3.4. Башкарма комитет түбәндәгеләргә хокуклы:
3.4.1. Әлеге Килешүне үтәү белән бәйле аңлатмалар бирүне сорап, Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә.
3.4.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, Тәртиптә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Килешү буенча бурычларын үтәмәгән һәм тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.
4.2. Бүтән бюджетара трансферт, әгәр Бүтән бюджетара трансферт түләүгә бирелгән акчаларның максатчан билгеләнеше буенча тотылмавы һәм (яки) дөрес булмаган хисапның тапшырылуы яки аның бөтенләй тапшырылмавы, әлеге Килешү һәм Тәртип шартларының бозылуы ачыкланса, 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кереме итеп кире кайтарылырга тиеш.
4.3. Бүтән бюджетара трансфертны кире кайтару өчен билгеләнгән срок бозылганда, Министрлык Килешүнең 4.2 пунктында күрсәтелгән срок беткән көннән алып 30 көн эчендә Бүтән бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.
4.4. Бүтән бюджетара трансфертларның агымдагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча файдаланылмый калган өлеше агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кереме итеп кире кайтарылырга тиеш.
4.5. Хисап финанс елында файдаланылмый калган Бүтән бюджетара трансфертка ихтыяҗ булу турында Министрлык карары нигезендә күрсәтелгән Бүтән бюджетара трансфертның калган өлешеннән артып китмәгән күләмдәге акчалар агымдагы финанс елында күрсәтелгән Бүтән бюджетара трансферт бирү максатларына туры килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итә өчен элек бирелгән Башкарма комитетка кире кайтарылырга мөмкин.
4.6. Тәртип һәм әлеге Килешү нигезендә алынган Бүтән бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кереме итеп күчерелмәгән булса, күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты кереме итеп мәҗбүри түләттерелергә тиеш.

4.7. Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан форс-мажор шартлар барлыкка килгән очракта азат ителәләр.

Форс-мажор шартлар дигәндә Яклар дөрес саклык белән эш йөрткәндә аларга бәйле булмаган сәбәпләр аркасында бурычларын тиешенчә үти алмаган шартлар аңлашыла, аерым алганда, мондый шартларга Килешүдә каралган бурычларның тиешенчә үтәлешен юкка чыгара торган хәрби хәрәкәтләр, табигать бәла-казалары керә.

Форс-мажор шартлар барлыкка килгәндә Яклар күрсәтелгән шартлар барлыкка килү турында бер-берсенә өч көн эчендә хәбәр итәргә тиеш.

4.8. Башкарма комитет Бүтән бюджетара трансфертның максатчан файдаланылуы, шулай ук Министрлыкка әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөреслеге, тулылыгы һәм үз вакытында тапшырылуы өчен җаваплы була.

4.9. Министрлык, алынган Бүтән бюджетара трансфертның тотылуына кагылышлы документлар тапшырылмаган очракта, Бүтән бюджетара трансферт билгеләнгән максатына тотылмаган очракта, шулай ук дөрес булмаган йә ялган документлар тапшырылган очракта, Килешүне вакытыннан алда өзү турында Башкарма комитетка хәбәрнамә җибәрү юлы белән Килешүне бер яклы өзәргә хокуклы.

4.10. Башкарма комитет, Килешүнең 4.9 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң, Бүтән бюджетара трансферт суммасын әлеге Килешүнең 4 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кереме итеп кире кайтаруны башкарырга тиеш.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Яклар арасында әлеге Килешүне үтәү белән бәйле барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, беркетмәләр яки бүтән документлар рәсмиләштереп, сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешелмәгә очракта, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Әлеге Килешү Якларның һәркайсы исеменнән эш йөртергә хокуклы затлар тарафыннан имзаланган датадан үз көченә керә һәм әлеге Килешү буенча 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була. Килешүнең гамәлдә булуы туктатылу Якларны әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәүдән азат итми.

5.3. Килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр, өстәлмәләр бары тик язма рәвештә төзелгән һәм Якларның вәкаләтләр бирелгән вәкилләре тарафыннан имзаланганнан соң гына гамәлгә кергән була.

5.4. Килешүдә җайга салынмаган мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җайга салына.

5.5. Килешү Якларның үзара килешүеннән соң, суд карары буенча яки Килешүдә каралган шартлар барлыкка килгән очракта вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

5.6. Килешү буенча бөтен бәхәсләр Яклар тарафыннан Министрлыкның урнашу урыны буенча судка мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

5.7. Килешүне имзалап, Башкарма комитет Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Бүтән бюджетара трансферт бирү шартларының үтәлешен, максатларын һәм тәртибен тикшерүне гамәлгә ашырырга ризалыгын белдерә.

5.8. Килешү тигез юридик көчкә ия 3 нөсхәдә төзелде, 2 нөсхә - Министрлык өчен, 1 - Башкарма комитет өчен.

**6. Якларның адреслары һәм реквизитлары**

**Татарстан Республикасы**
**Икътисад министрлыгы**:

Юридик адрес:
Банк реквизитлары:
Банк учреждениесенең исеме
БИК
к/с
р/с
Лицевой счет:
ИНН/КПП
ОГРН
ОКТМО

**Татарстан Республикасы __________________**
**муниципаль районының Башкарма комитеты**

Юридик адрес:
Банк реквизитлары:
Банк учреждениесенең исеме
БИК
к/с
р/с
Лицевой счет:
ИНН/КПП
ОГРН
ОКТМО

Татарстан Республикасы
икътисад министры

________________/______________/

Татарстан Республикасы
_________________________ муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
_______________/ ______________/

20 ____ елның
______________, № ___________

Килешүгә
1 нче кушымта

# Бүтән бюджетара трансфертны тоту рөхсәт ителгән чаралар исемлеге

- социаль әһәмиятле объектларда (авыл мәдәният йортлары, һәйкәлләр, күперләр

һәм башкалар) төзелеш-монтаж һәм ремонт эшләре;
- авыл хуҗалыгы техникасын (трактор, кар җыю машинасы һәм башкалар) сатып алу;
- юл-урам челтәрен ремонтлау (вак таш салу, тишекләрне ямау) һәм тротуарлар салу;
- ял итү урыннарын (парклар, скверлар һәм башкасы) төзекләндерү;
- зиратларны төзекләндерү (киртәләр, чүп-чар баклары һәм башкаларны кую);
- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыкларын сатып алу һәм урнаштыру;
- су торбалары челтәрләрен төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау;
- урам яктырткычларын кую һәм ремонтлау.

Бүтән бюджетара трансфертны тоту тыелган
чаралар исемлеге

проект-смета документациясен эшләү;
- административ биналарны ремонтлау;
- администрацияләр биналары өчен җиһаз сатып алу;
- үлән чабу, агачлау аудару, төпләрне тамырларны белән казып чыгару;
- кар көрәү;
- офис техникасын (компьютер, принтер, фототехника, музыкаль җайланмалар һәм башкасы) сатып алу;
- канцелярия товарларын сатып алу;
- костюмнар, кием, шторалар, портьерлар һәм башканы тектерү;
- ягулык сатып алу;
- гражданлык җаваплылыгын иминләштерү;
- әлеге Килешүнең 1.2, 1.3 пунктларына каршы килә торган башка чаралар.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>икътисад министры<br><br><br>_________________/_____________/ | Татарстан Республикасы<br>________________________ муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе<br>_________________/ ____________/ |

20 ____ елның

____________, № __________

Килешүгә
2 нче кушымта

__________________________ муниципаль районы авыл җирлеге 2018 елда Бүтән бюджетара трансфертларны тотарга планлаштырган

чаралар исемлеге

| № т/б | Авыл җирлегенең исеме | Чараның исеме | Бүтән бюджетара трансфертны тоту юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |

Татарстан Республикасы
икътисад министры

___________________/_______________/

Татарстан Республикасы
___________________________
муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

___________________/ ______________/

20 ____ елның ______________,

№ ___________

Килешүгә
3 нче кушымта
Финанс белән тәэмин итү

чыганагы

Бүтән бюджетара трансферт булган
чыгымнар турында хисап

20__ елның «__» __________ на (нә)

Алучының исеме _______________________________________________

Ешлык: квартал, ел

Исәпләү берәмлеге: сум (икенче дистә күрсәткеченә кадәрге төгәллек белән)

| Күрсәткеч исеме | Сумма | | Чыгымнарның башкарылуын раслый торган түләү документлары реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Йомгагы ел башыннан арта барганда | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ел башына<br>Бүтән бюджетара трансфертның калган өлеше, барлыгы: | | | |
| шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешлеге | | | |
| расланган ихтыяҗ | | | |
| Кергән акча, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджетыннан | | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы: | | | |
| алардан: | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылды: барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеше буенча тотылмаганнар | | | |
| штраф санкцияләре кулланылу нәтиҗәсендә | | | |
| Хисап чоры ахырына Бүтән бюджетара трансфертның калган өлеше, барлыгы: | | | |
| шул исәптән:<br>шул ук максатларга җибәрелүе таләп ителә | | | |
| кире кайтарылырга тиеш | | | |

Хисапка түләү документларының тиешенчә таныкланган күчермәләре беркетеп бирелә.

Алучы _________________ __________ ____________________________

(вазыйфа) (имза) (имзаны аңлатып язу)

Башкаручы _________________ ________________ ________________

(вазыйфа) (Ф.И.А.и.) (телефон)

«___» __________, 20__ ел

Татарстан Республикасы
икътисад министры

___________________/______________/

Татарстан Республикасы
__________________________ муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

___________________/ ______________/

20 ____ елның ______________,

№ ___________

Килешүгә

4 нче кушымта
Форма

**Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә грантлар бирүгә**
республика конкурсында җиңүче тарафыннан Бүтән бюджетара трансфертның файдаланылуы турында
ФИНАНС ХИСАБЫ

Моның белән авыл җирлегенә Бүтән бюджетара трансфертны бирү турында _____ елның ___________ , __________ номерлы Килешү нигезендә бирелгән Бүтән бюджетара трансфертның Татарстан Республикасы _________________ муниципаль районының _________________ авыл җирлеге яшәешен турыдан-туры тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгытуга, авыл җирендә урнашкан торак пунктларны социаль инфраструктура һәм тышкы төзеклек объектлары белән җиһазлауга һәм Татарстан Республикасы авыл җирлегенең социаль әһәмиятле башка мәсьәләләрен хәл итүгә тотылуын раслыйм.

| Чараларның, башкарылган эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең исемнәре, аларны үткәрү срогын һәм аларда катнашучыларны (башкаручыларны) күрсәтеп | Чараларның, эшләрнең башкарылуын яки хезмәтләрнең күрсәтелүен раслый торган документларның исемнәре һәм реквизитлары | Барлыгы, сум |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | БАРЫСЫ БЕРГӘ: |

Хисапка документларның тиешенчә таныкланган түбәндәге күчермәләре беркетеп бирелә.
1. Әлеге хисапның күрсәткечләрен раслый торган документлар ______ бит, ________ нөсхә

Татарстан Республикасы
икътисад министры

_________________/___________/

Татарстан Республикасы
_________________________
муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
_________________/_____________/

20 ____ елның _____________,

№ __________

Килешүгә
5 нче кушымта

**Хисап белән бирелә торган документларның**

ИСЕМЛЕГЕ

- финанс хисаплары (шартнамәләргә кушымталар - оригиналлар)
- аукционнарга йомгак ясау беркетмәләре (таныкланган күчермәләр);
- муниципаль контрактлар (таныкланган күчермәләр);
- шартнамәләр (таныкланган күчермәләр);
- локаль ресурс смета исәп-хисаплары (таныкланган күчермәләр);
- счет-фактуралар (таныкланган күчермәләр);
- түләүгә счетлар (таныкланган күчермәләр);
- товар накладнойлары (таныкланган күчермәләр);
- туры килү сертификатлары (таныкланган күчермәләр);
- башкарылган эшләрнең бәясе турында белешмәләр (таныкланган күчермәләр);
- башкарылган эшләр актлары (таныкланган күчермәләр);
- банкларның түләү йөкләмәләре (финанс-бюджет палатасы мөһере белән)
- һәр чараның эш башланганчы, эшләрне башкару вакытында һәм эшләрне башкарганнан соң төрле ракурслардан төшерелгән фотосурәтләре.

Сатып алынган техникага өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:
- паспорт (таныкланган күчермә);
- гарантия талоны (таныкланган күчермәләр);
- алу-тапшыру актлары (таныкланган күчермәләр);
- теркәү турында таныклык (таныкланган күчермә);
- техник тикшерү узу турында таныклык (таныкланган күчермә);
- транспорт чарасын авыл җирлеге балансына кую турында боерык (таныкланган күчермә);
- фотографияләр (шул исәптән номер билгеләре белән).

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>икътисад министры<br><br>__________________/_____________/ | Татарстан Республикасы<br>__________________________<br>муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе<br>__________________/_____________/ |